КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 26 гыйнвар г.Казань № б-79

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. 2026 елның 14 февралендә «Лыжня России – 2026» XLIV ачык Бөтенроссия массакүләм чаңгы узышын һәм «Лыжня Татарстана – 2026» республика массакүләм ярышларын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, 2026 елның 14 февралендә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Лыжня России – 2026» XLIV ачык Бөтенроссия массакүләм чаңгы узышын әзерләү һәм үткәрү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Лыжня Татарстана – 2026» республика массакүләм ярышларын үткәрүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә ярышларда үз хезмәткәрләренең катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге ярышларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин